# Илебезнең батыр уллары

Дәү әтиемнең әнисе
Инде бик йөри алмый
Сугыш турында сөйләсә
Күз яшьләрен тоялмый

Әби бабайлар безнең горурлык
Исән булсыннар телибез саулык
Исәннәрнең белик кадерен
Үлгәннәрнең белик каберен

Исән кайтса да бабайлар
Бик күпне күреп кайткан
Илдә тынычлык булсын дип
Күпләре үлеп калган

Әнә күктә күгәрченнәр оча
Алар да тынычлык кошлары
Сугыш бетеп тизрәк кайтсыннар
Илебезнең батыр уллары